| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 26.09.2025 | Баулы шәһәре | № 3 |

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе вазыйфасын
биләүгә конкурс игълан итү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 19 статьясы, «Баулы муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы нигезендә» Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә, Баулы муниципаль район Советы вәкаләтләре срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар 2025 елның 2 октябреннән 22 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителергә тиеш: Баулы ш., Куйбышев ур., 20 й., каб. №310, 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр һәркөнне, ял көннәреннән тыш, тел. (85569) 6 07 13.

2. Конкурс комиссиясенә 2025 елның 5 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Баулы муниципаль район Советы бинасында түбәндәге адрес буенча Конкурс үткәрергә: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә конкурс нәтиҗәләрен һәм Баулы муниципаль районы Советына кандидатлар турында мәгълүмат тапшырырга.

3. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең 6 кешедән торган сан составын расларга.

4. Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составының яртысын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны 2025 елның 2 октябрендә «Хезмәткә дан» («Слава труду») газетасында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров